The investigator brought Babich's manuscript that was sent to the press in 1935 from the archive of the Bashkir State Publishing House as "material evidence" against Nasyri. The fact that Babich's manuscripts were indeed prepared for publication by Nasyrov is further confirmed by another document that was poorly translated into Russian. In this letter, sent on April 8, 1935 to the Bashkir State Publishing House, Sayfi Kudash advised I. Nasyrov to publish Babich's collection as an academic publication. He emphasized the importance of taking the preparation of the scientific publication seriously, systematizing the poet's works chronologically and thematically and indicating the story behind this publication. Under the influence of the ideology of that era, he recommended to "process" Babich's works through the perspective of proletariat's ideology, keeping in mind that Z. Validi was one of the first agitators. The content of the article evidences the author's positive attitude and respect for the personality and creativity of Sh. Babich.

The collection of Babich's works, prepared for publication, became one of the "biggest accusations" thrown at I. Nasyrov, who was arrested during the first wave of the personality cult. I. Nasyri wrote another letter from Belebeyevskaya prison to the People's Commissariat of Internal Affairs of the USSR with the recognition of his political mistakes during the preparation of Babich's works for publication: "Regarding my attempt to publish the works of the Validovets and counter-revolutionary Babich. I gave my testimony on how I took up this work on behalf of the Kultprop of the Regional Committee of the C.P.S.U. (B). As soon as I realized that I had done something wrong, I immediately refused. I wrote a letter of refusal to the editor-in-chief of "Bashgiz" Ishemgulov (1935)" (literal translation – G. S.). Apparently, the writer and textual critic, unable to withstand the spiritual humiliation and physical suffering, was forced to admit that Sh. Babich was a "validovets", a "petty-bourgeois nationalist", and a "counter-revolutionary" poet.

As it turns out, the Bashkir State Publishing House included the publication of Sh. Babich's works in its plan for the year 1936. In the list of manuscripts submitted to the publishing department of Bashgiz on January 1, 1936, there is also a book by Babich. Contract No. 214 between I. Nasyri, the author of the collection "Бабич әсәрләре", and the publishing house has survived (the date is unknown. – G. S.). The cost of the contract is set for 5400 rubles, the author is said to have received a 25 per cent prepayment [Bashkortostan Republichynyң Milli arkhivy. Ф -749. Оп.1.Д.141. Б. 171 ]. Hence, I. Nasyri's statement "I refused, I didn't do it" does not seem to be true, and it is possible that he did not complete the work he once started.

These studies give reason to conclude that the works included in the books, published in Bashkortostan and Tatarstan, which are still preserved to this day, are mostly taken from the collection prepared by Zabih Iskuzhin, although the process of collecting and publishing Babich's works was widely spread in the early 1930s in Bashkortostan. The collection, prepared for publication by I. Nasyri, was destroyed as it was the "material evidence" attached to that criminal case, because, after the trial, the "material evidence" items are returned to the owner only upon request and are destroyed if there is no claimant. In our opinion, in 1937–1938, there were no applications to the court and the investigative authorities demanding the return of Babich's collection.

This opinion is confirmed by a letter from Imai Nasyri's wife, written in 1957 to the All-Union Administration for the Protection of Copyrights under the USSR Writers' Union. "Babich's works, collected by my husband in the 30s, that are published and partially remain unpublished in the Tatar press, indeed make up a significant part of the poet's literary heritage. Nevertheless, I was convinced that this collection was not ready for publication: the collected material was not sufficient to

[5] Khasanov Habib Valievich - (1899-1938) – a public figure, translator, editor of the Russian-Bashkir dictionary. He was in prison during that time. His name was also on the list of 44 people who were sentenced to death on July 10, 1938. The victim of repression.

be published as a complete collection, sources or origins of Babich's works were not identified, the poems were not compared to the originals, the whole material was given in Arabic and Latin scripts that were already out of use" (literal translation. – G. S.) [Rəsəi Fəndər academyhynyң…, Ф-50. Оп. 1. Д. 83. Б. 1].

Z. Iskuzhin became fascinated by Sh. Babich's literature and wrote a scientific dissertation, devoted to the study of his literary heritage. Unfortunately, a significant part of the research work has not been preserved, yet several chapters have been found in his notebooks. The graduate student defined six areas of research on the poet's literature: 1. Babich is a Petty Bourgeois Democratic Poet of the Tatar and Bashkir Social World before the October Revolution; 2. Realism in Babich's Literature; 3. Lyrical Poetry of Babich; 4. Babich's Satire; 5. Poetic Language of Babich; 6. Babich and Folklore. As a possible topic No. 7, he mentions "Our Poetic Culture before the Revolution and the Study of Babich". Z. Iskuzhin emphasizes the positive impact of the integrated approach to the poet's work: "It is not enough to be just a linguist or a writer to collect, compile and study Babich's work. You have to be a historian and a politician" (his note on a grey notebook – G. S.). While studying the life and literary work of the leader of the Bashkir national movement Babich, the young scientist uses the work "Башкирское национальное движение в 1917–1920 // Тезисы Башобком ВКП (б)" ("Bashkir National Movement from 1917 to 1920 // Theses of the Bashobkom of the CPSU (B)"), published by Karim Idelguzhin as one of the significant sources [Idelguzhin].

Research, aimed at the study of the events in Sh. Babich's life, his stance in the socio-political situation after the October Revolution of 1917 and in the historical process, and the identification of his literary works, written in this tragic period, is still underway. Fortunately, new important facts and information are still being discovered. For example, the proverbial fate of Babich's poem "Башкорт халкына" ("To the Bashkir People") is a clear example of this. Although it was previously recognized that this work was created by the poet, the text of the work remained unknown. As the scholar's writings were moving from hand to hand, after the death of Zabih Iskuzhin, a small part of his archive attracted attention of Naky Isanbet, the People's Writer of Tatarstan, a playwright, poet, folklorist and translator. Shehzade Babich's poem "Башкорт халкына" was also among these materials. According to the scholar, "This work, which should have become one of the most honourable poems of Babich, has not yet been published anywhere in the mass media. That is why we don't have it at our fingertips, we were able to acquire it thanks to the memories of Babich's friends, who were with him during the transition of the Bashkir people to the Soviet's side" [Isənbət, 2021].

Finally, this verse reached the Bashkir and Tatar people and received a great deal of public attention.

There are also different opinions about the last days of Sh. Babich's short life and his tragic death. Different versions of the untimely and tragic death of this heroic person are described in monographic works and various sources [Gyilmanov, 1990, p. 12], [Gainetdinov, p. 224], [Ganieva, p. 140], [Babich, 2009, pp. 140–141], [Gainetdinov, Ganieva, pp. 351–352], [RF Federal imenlek …, F-10. B–4129. P. 5] and others.

M. Khabetdinova, studying the materials of N. Isanbet's archive, came across the data that shed light on the last days and the tragic death of Sh. Babich: "Relying on the memories of Ziya Iskuzhin, N. Isanbet describes how and by whom Sh. Babich was killed. Zia Iskuzhin wrote in his diary that Sh. Babich was killed by the Preobrazhensky Revkom at the end of March 1919" [Khəbetdinova, 2021]. The archive of the famous Tatar writer and scientist N. Isanbet includes a typewritten copy of the 77-page work "Шәехзадә Бабич", completed on January 10, 1965. On January 15, 2011, M. Khabetdinova presented N. Isanbet's article "Бабичның үтерелүе" ("The Assassination of Babich") in the "Мәдәни җомга" newspaper. According to the scholar, this article sheds light on the Sh. Babich's tragic murder, which was "quite ambiguous". Approaching this injustice from the historical and political perspective, N. Isanbet gives an excerpt from Z. Iskuzhin's material. Babich was assassinated in late March 1919 by the Preobrazhensky Revkom, which represented a national antagonistic tactic for the local population" [Kara: Isənbət, 2021]. To avoid misunderstandings, the author of the article gives an excerpt from the written appeal of V. V. Kuibyshev about the reputation of this Revkom. "Due to the scepticism of some Soviet institutions towards the local population (*N. I.*), "Pure Russian Revcoms" were established, some elements of which had previously exploited the Bashkir people and were quite hostile to them. < > Revolutionary activists, poets and artists of Bashkortostan have been shot dead by these criminal organizations" [Kara: Isənbət, 2021]. N. Isanbet, after studying the

latest published supplementary material in the Bashkir press in addition to Z. Iskuzhin's documentary sources, wrote the following: "The fact that Babich was killed based on national hostility, chauvinism, and the great power struggle is also confirmed and further substantiated in these materials" [Isənbət, 2021].

## Results

1. Brought up in the national and cultural traditions of the Kazakh-Kyrgyz, Tatar, and Bashkir peoples, Sh. Babich, was spiritually nourished by them. He quickly became a versatile and creative personality and made a significant contribution to the development of their national literature and art.
2. The life and creative work of the poet coincide with a very complex, tumultuous period of the historical process. The time of troubles and great disasters made it difficult for the poet to choose historical and ideological orientations and identify his national beliefs and romantic ideals. Socio-political events had a great influence on the determination of Babich's position, prominence and the importance of his poetry in the culture of the Turkic peoples.
3. The studies of Babich's life and literary activity in the context of the socio-political situation and culture show that drastic social and cultural changes have had a great impact on writers' literary works and life. The "transition" period allows us to identify the trends in the development of national literature and the changes in the ideological and spiritual orientations of writers and poets of that time.
4. Sh. Babich's collections, which were compiled but never published, have a complicated history. The Tatar and Bashkir intellectuals' noble actions, aimed at popularization of the life path and literary values of the heroic poet, were defined as a "terrible crime" during the years of I. V. Stalin's personality cult and led to their repression.

## Conclusion

Our research reveals a century-long history of the studies devoted to the life and spiritual world of Sh. Babich. It is with sadness that we see that Sh. Babich, who grew up to be a national symbol and a remarkable wordsmith, soon became a victim of social cataclysms, ideological struggle, and terrorism. Although there are various stages in the evaluation of the poet's personality, they always start with one-sided erroneous assessment, when the poet went from one extreme to the other. This area undoubtedly needs further research, thus the article determines the prospects for the future study of the topic.

**References**


Əgləm, M. (1995). *Tatarnyң tanylmagan məshhүr zaty* [Tatar's Unrecognized Celebrity]. Kazan utlary. No. 1, pp. 160–164. (In Tatar)

*Babich. Ədiplerebez: biobibliographik beleshməlek: 2 tomda: 1 tom* (2009) [Babich. Our Writers: A Biobibliographic Reference: In 2 Volumes: Volume 1]. Төз. R. N. Dautov, R. F. Rahmani. Pp. 139–142. Kazan, Tatar kit. nəshr. (In Tatar)

Babich, Sh. (1925). *Shəekhzadə Babich shigyrləre* [Poems by Shehzade Babich]. P. 32. Moscow, USSR khalyklarynyң Yzək basmasy, (In Tatar)

Babich, Sh. (1994). *Beҙ үҙbeҙ - bashҡorttar: shiғyrҙar, poemalar, feuletondar, məҡələlər, khattar, kөndəlektr* [Five of Them Are Bashkir: Verses, Poems, Feuilletons, Articles, Letters, Diaries]. Төҙ. Bash hүҙ, həm aңl. avtory R. Bikbaev]. P. 583. Өfө, Kitap. (In Bashkir)

Babich, Sh. M. (1980). *Zəңgər Kyrlar* [Blue Songs]. Tөz., keresh məkalə avtory G. Gyilmanov. P. 542. Kazan, Tatar kit. nəshr. (In Tatar)

Babich, Sh. M. (1997). *Issemnur bakchasy. Shigyrlər, epigrammalar* [The Garden of Names. Poems, Epigrams]. P. 111. Kazan, Tatar kit. nəshr. (In Tatar)

Babich, Sh. M. (1958). *Sailanma əsərlər* [Selected Works]. P. 154. Kazan, Tatar kit. nəshr. (In Tatar)

*Bashkortostan Republichynyң Milli arkhivy* [National Archives of the Republic of Bashkortostan]. F – 749. Op.1. D.141. 171. (In Bashkir)

Bikbov (1923). *Shəyehzada Babichtyң ҡul'yaҙmahy həm keyemdəre* [Shehzade Babich's Manuscripts and Clothes]. Bashҡortostan. 3 p. (In Bashkir)

*Epik shigriiat. XX yөz bashy* (2002) [Epic Poetry. Early Twentieth Century]. Tөz .: F. Z. Iakhin. Pp. 17–31. Kazan, TaRIKH. (In Tatar)

Gainetdin, M. V. (1991). *Babich həm anyң kitaby* [Babich and His Book]. Kazan utlary. No. 11, pp. 186–188. (In Tatar)

Gainetdin, M. V. (2001). *Shəekhzadə Babich* [Shekhzade Babich]. Hakykat yulynnan. Kazan, pp. 206–224. (In Tatar)

Gainetdinov, M., Ganieva, R. (2016). *Shəekhzadə Babich.* [Shekhzade Babich]. Tatars ədəbiyaty tarikhy: sigez tomda. 4 t .: XX yөz bashy. Tөz. R. F. Rahmani; fən. mөkh. R. K. Ganieva]. Pp. 340–352. Kazan, Tatar kit. nəshr. (In Tatar)

Ganieva, R. K. (2002). *Romanticheskie motivy tvorchestva Shayekhzade Babicha* [Romantic Motifs of Shaekhzade Babich's Work]. Tatars ədəbiiaty: traditionalər, baglanyshlar. Pp. 122–141. Kazan. (In Russian)

Gosman, Kh. (1964). *Egermenche ellard Tatar poeziiase* [Tatar Poetry in the Twenties]. 397 p. Kazan, Kazan Nashriyat Universities. (In Tatar)

Gyilmanov, G. (1990). *Koiashly shigriyat. Zəңgər Kyrlar* [Sunny Poetry. Blue Songs]. Kazan, pp. 7–14. (In Tatar)

Gyilmanov, G. (1993). *Məkhəbbət tokyny. Issemnər bakchasy* [The Prisoner of Love. The Garden of Names]. Shigyrlər, epigrammalar. Pp. 5–14. Kazan. (In Tatar)

Ibragimov, G. (1978). *Vakytsyz həlak buldy* [Untimely Death]. Əsərlər sighez tomda. 5 volumes: ədəbiiat həm səngat turnda məkalələr hezmətlər (1910–1933) . Təz., tekst., isk. həm aңl. əzerl. Khəsənov M. Kh., Gainanov R. R. Pp. 314–329. Kazan, Tatar.kit.nəshr. (In Tatar)

Idelguzhin, K. (1934). *Bashkirskoe natsional'noe dvizhenie v 1917–1920* [Bashkir National Movement in 1917–1920]. Tezisy Bashobkom VKP (b). Ufa, izd. Bash. TSIK. (In Russian)

Isənbət, N. (2021). *Babichnyң yterelуe* [Assassination of Babich]. Mədəni zhomғa. 15 Guinvar. No. 1 (10 Gynvar, 1965, Kazan). (In Tatar)

Isənbət, N. *Shəekhzadə Babich* [Shehzade Babich]. Arkhiv materialy, kolyazma. 57 p. (In Tatar)

*Iskuzhin Ziia Gazimovich.* URL: Tsentr pis'mennogo i muzykal'nogo naslediia IYALI im. G. Ibragimova AN RT (miras.info). (In Tatar)

Iskuzhin, Z. (1936). *Tuкai turnda Babich* [Babich about Tukay]. Sovet ədəbiiaty. No. 5, pp. 67–68. (In Tatar)

Isənbət, N. (1967). *Shəekhzadə Babich: Istəlek* [Shehzade Babich: Memory]. Kazan utlary. No. 6, pp.127–134. (In Tatar)

Kharrasova, R. (2019). *Fərvaz Miңnullin - tənkyitche* [Farvaz Minnullin as a Critic]. Fərvaz Miңnullin (1934–2009). Pp. 3–13. Kazan, RIC “Shkola”. (In Tatar)

Khabutdinova, M. M. (2020). *Obraz Sh. Babicha v vospominaniiakh N. Isanbeta* [The Image of Sh. Babich in the Memoirs of N. Isanbet]. Aktual'nye problemy natsional'nykh literatur i otechestvennogo literaturovedeniia: materialy Vserossiyskoi nauchno-prakticheskoi konferentsii (s mezhdunarodnom uchastiem), posviashchennoi 125 – letiiu so dnia rozhdeniia vidnogo bashkirskogo poeta, obshchestvennogo i gosudarstvennogo deiatelia Shekhzady Babicha. Pp. 197–222. Ufa, RITS BashGU. (In Russian)

Khəbetdinova, M. M. (2021). *Ədəbiiat belemendə Zyya Iskuzh* [Ziya Iskuzh in Literary Studies]. Mədəni җomga. 15 Gynnvar. # 1. (In Tatar)

Kitabov, Ғ. (1957). *Babich turahynda iemdə kalғandar* [Remembering Babich]. Əҙəbi Bashҡortostan, Өfə, No. 4, p. 41. (In Bashkir)

Kudashev, A., Lokman Җ. (1936). *Nekrolog* [Obituary (Z. Iskuzhin)]. Bashkortostan, November 27 (No. 271). (In Bashkir)

Minegulov, H. Y. (1995). *Olug talent (Shaekhzad - Babich turenda)* [Great Talent (About Shehzade Babich)]. Miras. No. 9, pp. 46–61. (In Tatar)

Nəҙepғolov, M. (2007). *Uylandyra, içkərtə, habaк birə* [Think, Rehearse, Teach]. Bүs. Yaҙmalar. (təҙəүsehe - Yanbaev I. K.). P. 309. Өfə, Kitap. (In Bashkir)

Nurullin, I. (1982). *XX yөz bashy Tatars ədəbiyaty* [Tatar Literature of the Early Twentieth Century]. Urta məktəp ukytuchylary, student həm yugary class uuchylary өchen dəreslek-kullanma. Pp. 222–225. Kazan, Tatar kit. nəshr. (In Tatar)

*RF Federal imenlek kheҙmətteneң Bashкortostan buiynsa idaralyғy arkhivy* [Archive of the FSB Office of the Russian Federation for Bashkortostan]. F–10. B–4129. (In Bashkir)

*Rəsəi Fəndər academyhynyң Өfə federal tiksherener үҙәgeneң ғilmi arkhivy* [Scientific Archive of the Ufa Federal Research Center of the Russian Academy of Sciences]. F–50. Op. 1. D. 12. (In Bashkir)

Salamatova, G. D. (2020). *Sh. Babichtyң əҙəbi miraçynyң yaҙmyshy (1918–1937 iyldarҙaǧy osor)* [The Success of Babich's Literary Heritage (1918–1937)] Aktual'nye problemy natsional'nykh literatur i otechestvennogo literaturovedeniia: materialy Vserossiyskoi nauchno-prakticheskoi konferentsii (s mezhdunarodnom uchastiem), posviashchennoi 125 – letiiu so dnia rozhdeniya vidnogo bashkirskogo poeta, obshchestvennogo i gosudarstvennogo deyatelia Shaykhzady Babicha: Ufa, RITS BashGU, pp. 137–143. (In Bashkir)

*Shəyehzada Babich haкynda tələktur* (1994) [Shekhzade Babich’s Story]. Pamyat' o Sheykhzade Babiche. Өfə: Kitap-1994. (In Bashkir)

*Tatar poeziase antologiiase* (1992) [Anthology of Tatar Poetry]. 1 kitap. Pp. 452–461. Kazan, Tatar kit. nəshr. (In Tatar)

*Tatar ədəbiiaty tarikhy: 6 tomda. 3 t .: XX gasyr bashy* (1986) [History of Tatar Literature: In 6 Volumes. Volume 3: Early Twentieth Century]. Pp. 247–251. Kazan, Tatar.kit.nəshr. (In Tatar)

*Tatarstan fəndər academyhy F.Ibrahimov issemendəge Tel, əҙəbiət həm sənғət institutesң Yҙma miraç həm musical үҙəge* [Joint Heritage and Musical Center of the Institute of Language, Literature and Art named after J. Ibragimov of the Academy of Sciences of Tatarstan]. F. 47. Op. 1 D. 5. P. 19. (In Tatar)

*Tatarstan fəndər academyhy F.Ibrahimov issemendəge Tel, əҙəbiət həm sənғət institutesң Yҙma miraç həm musical үҙəge* [Joint Heritage and Musical Center of the Institute of Language, Literature and Art named after J. Ibragimov of the Academy of Sciences of Tatarstan]. F. 47. Op. 2 D. 66. P. 1. (In Tatar)

*Tatarstan fəndər academyhy F.Ibrahimov issemendəge Tel, əҙəbiət həm sənғət institutesң Yҙma miraç həm musical үҙəge* [Joint Heritage and Musical Center of the Institute of Language, Literature and Art named after J. Ibragimov of the Academy of Sciences of Tatarstan.]. F. 47. Op. 2 D. 66. Pp. 2 -3. (In Tatar)

*Tatarstan fəndər academyhy F.Ibrahimov issemendəge Tel, əҙəbiət həm sənғət institutesң Yҙma miraç həm musical үҙəge* [Joint Heritage and Musical Center of the Institute of Language, Literature and Art named after J. Ibragimov of the Academy of Sciences of Tatarstan.]. F. 47. Op. 2 D. 66. P. 3. (In Tatar)

Zagidullina, D. F. (2005). *Shaekhzadə Babichnyң iҗat yuly: məgərifətchelektən shartly surətkə taba* [Shehzade Babich's Creative Path: From Enlightenment to A Conditional Image]. Rəmiev S. L. Əsərlər. S. L. Rumiev, Sh. M. Babich. Pp. 149–166. Kazan. (In Tatar)

*Zəңgər Kyrlar* (1990) [Blue Songs]. Təz., keresh məkalə ed. G. Gyilmanov. 543 p. Kazan, Tatar kit. nəshr. (In Tatar)

# 1920-1950 ЕЛЛАР ИҖТИМАГЫЙ ҺӘМ МӘДӘНИ КОНТЕКСТЫНДА ШӘЕХЗАДӘ БАБИЧ МИРАСЫ

**Гөлчәчәк Дәүләтбай кызы Саламатова,**
З. Исмәгыйлев исем. Уфа дәүләт сәнгать институты,
Россия, 450008, Уфа ш., Ленин ур., 14 нче йорт,
gulsyasyak.salamatova.76@mail.ru.

Мәкаләдә башкорт һәм татар халыкларының шагыйре Шәехзадә Бабичның тормыш юлы һәм иҗаты иҗтимагый-сәяси вазгыять һәм мәдәният контекстында бәяләнә. Дәүләт һәм күренекле шәхесләр архивларында, газета-журналларда, истәлек-хатирәләрдә һәм хатлардагы шагыйрь тормышына һәм рухи мирасына кагылышлы яңа материаллар системалаштырыла. Аерым әсәрләренең язылу тарихына, хронологиясенә ачыклык кертелә. Ш. Бабичның рухи мирасын саклап калуда Г. Ибраһимов, З. Искужин. Т. Чеңкәй, А. Кудашев, А. Насыри, Н. Исәнбәт һәм башкаларның эшчәнлеге бәяләнә, шушы уңайдан аларның эшчәнлегенә һәм тормыш фактларына да ачыклык кертелә. Шагыйрьнең басылып чыккан яисә нәшер ителүгә әзерләнеп тә дөнья күрмәгән җыентыкларының тарихы илнең идеологик һәм сәяси атмосферасы белән тыгыз бәйләнештә шәрехләнә.

**Төп төшенчәләр:** башкорт әдәбияты, татар әдәбияты, кулъязмалар, иҗтимагый вазгыять, мәдәният.

## Кереш

Шәехзадә Бабич башкорт, татар, казах төрки халыкларның әдәбияты һәм мәдәнияте тарихында зур урын тота. Табигый сәләткә һәм зур иҗат потенциалына ия булган Ш. Бабич фани дөньяда бик аз яши. Беренче бөтен дөнья сугышы, инкыйлаблар, гражданнар сугышы, социаль тетрәнүләр нечкә күңелле, шул ук вакытта гыйсъян рухлы Бабич шәхесенә зур йогынты ясый. Катлаулы һәм каршылыклы чор шагыйрьнең тарихи һәм идеологик ориентирларын сайлауны, милли ышанычларын һәм романтик идеалларын тормышка ашыруны катлауландыра. Аның гомере бик иртә, 24 яшьтә фаҗигале төстә өзелә. Бу талантлы шагыйрь яшьләй кулына каләм ала һәм бүген дә әдәби-эстетик кыйммәте бәяләнеп бетмәгән әдәби мирас калдыра. Ш. Бабичның әдәбият күгендә күтәрелеше татар халкы шагыйре Г. Тукайны югалткан көннәргә туры килә. “Аңа зур югалтуны тулыландырырга, бөек Тукай кулыннан төшкән каләмне күтәрергә һәм дәвам итәргә туры килә, - дип яза әдәбият галиме Р. Ганиева. – Ш. Бабичка әдәби эшчәнлегенең беренче адымнарыннан “Тукай мәктәбе шагыйре” дигән дан бирелде” (сүзгә-сүз тәрҗ. – *Г.С.*) [Ганиева, 2002, б. 124].

Ш. Бабич иҗатының өйрәнелү тарихы бай, һәр буын әдәбият галимнәрен аның шартлы-романтик фикерләүгә корылган бай иҗаты үзенә тарта. Аның әдәби эшчәнлеге, аерым аспектлары Г. Ибраһимов [Ибраһимов], Х. Госман [Госман], И. Нуруллин [Нуруллин], Н. Исәнбәт [Исәнбәт, 1967], Г. Гыйльманов [Зәңгәр җырлар], [Гыйльманов, 1993], М. Әгъләмов [Әгъләм], Х. Миңнегулов [Миңнегулов], М. Гайнетдинов [Гайнетдинов, 1991], [Гайнетдинов, 2001], Р. Ганиева [Ганиева], Д. Заһидуллина [Заһидуллина] һ.б.ларның хезмәтләрендә яктыртыла.

Үзгәртеп корулар башлангач, аның әдәби эшчәнлеген һәм тормыш сукмакларындагы аерым фактларны барлауга Г. Гыйльманов үзеннән зур өлеш кертте [Гыйльманов, 1990]. Совет чорында да, совет идеологиясенең басымы кимегән чорларда да идеологик сәбәпләр, матди кысынкылыклар һәм башка сәбәпләр аркасында, Ш. Бабичның әдәби әсәрләрен бастырып чыгару каршылыкларга очрый. Г. Гыйльманов әзерләгән китап та бу вакытта Татарстан китап нәшриятының баш

мөхәррире вазифасын башкарган Ф. Миңнуллин тырышлыгы белән басыла: “1990 елда Ш. Бабич җыентыгы дөнья күрде. Әле мөстәкыйльлек алынмаган еллар, әмма инде милли-иҗтимагый хәрәкәт көчәеп килә. Әнә шундый шартларда шагыйрь тупланмасына безнең коллыкка төшү тарихын ачыктан-ачык күрсәткән “Утрау” кебек әсәрләр керсен өчен дә, хезмәтләргә фатиха бирүче баш мөхәррир вазифасын Фәрваз Миңнуллин кебек кыю шәхеснең башкаруы кирәк иде” [Харрасова, б. 5].

XX - XXI гасыр чикләрендә башкорт һәм татар галимнәре талантлы шагыйрьнең иҗаты һәм тормышын, андагы “ак тап”ларны ачыклау мәсьәләсендә эзләнүләрен активлаштырды һәм бу юнәлештә уңышлы нәтиҗәләргә ирештеләр: Ш. Бабич [Бабич, Без үҙебеҙ...], М. Нәҙерғолов [Нәҙерғолов], М. Хәбетдинова [Хәбетдинова] һ.б.лар. Әдәбият галиме, фольклорист, текстолог Н. Исәнбәт архивында сакланган “Бабичның үтерелүе” дигән мәкалә, М. Хәбетдинова тарафыннан әзерләнеп, “Мәдәни җомга” газетасында басылып чыкты [Исәнбәт, 2021 ]. Шагыйрьнең соңгы көннәренә ачыклык керткән бу язма татар һм башкорт әдәби җәмәгатьчелегендә зур кызыксыну уятты.

Шәехзадә Бабичның әдәби мирасының язмышы бүгенге көндә күп кенә сораулар тудыра, чөнки шигырьләренең, хатларының, мәкаләләре һәм фельетоннарының күп өлеше басылмый калган. Шагыйрь көндәлекләренең дә язмышы билгесез. Билгеле булганча, теләсә нинди шартларда шигырь язып, йөргән җирләрендә ак кәгазьгә сүз энҗеләрен тезеп калдырып киткән талант иясе үзе дә иҗатына сакчыл карамаган. Бабич шигырьләре башкортның киң далалары, гражданнар сугышы чорында канга батырылган башкорт авыллары буйлап сибелә. Байтак өлеше эзсез югала, шәхси блокнотларда, альбомнарда сакланып калганнарына да басылмый калу, югалу куркынычы яный. Дәһшәтле елларда Бабичның шигырьләренең бер шәлкеме утка ташланып, көлгә әйләнәләр. Совет иле башкорт һәм татарның талантлы улының язмышына да, иҗатына да мәрхәмәтле булмады. Мәкаләдә Ш. Бабичның тормыш юлына һәм әдәби эшчәнлегенә караган язмаларны барлау, ачыкланганнарына иҗтимагый һәм әдәби-мәдәни контекстта бәя бирү, фикер-карашларны системалаштыру максаты куела. Шагыйрь биографиясе хакындагы дөреслектән ерак булган бәяләрне төзәтүдә, аны яңа фактлар, вакыйгалар белән баетуда, билгеле булмаган әдәби әсәрләренең язмышын ачыклап, иҗат әһеленең мирасын торгызуда фәнни хезмәт темасының актуальлеге һәм яңалыгы билгеләнә.

**Фәнни хезмәтнең материалы һәм методлары**

Ш. Бабичның тормыш юлы һәм әдәби эшчәнлеге хакында яңа мәгълүмат алып килгән дәүләт архивлары, тарихи чыганаклар, замандашлары китапханәләрендә, архивларында сакланып калган истәлекләр-хатирәләр, хатлар, шагыйрьнең әдәби әсәрләре, кульязмалары фәнни тикшерену эшенең материалы булып тора. Куелган максатка ирешү өчен, культура-тарих, чыгыштырма-тарихи, биографик методларга мөрәҗәгать ителде. Культура–тарих мәктәбенең әдәби эшчәнлекнең халыклар тормышы, чор-заман, тирәлек белән бәйләнеше хакындагы төп кануны Ш. Бабичның рухи мирасын башкорт һәм татар халыкларының тарихы, әдәби барышы һәм мәдәнияте белән тыгыз бәйләнештә карарга мөмкинлек бирде. Шулай ук биографик метод һәм әдәби күренешне аның барлыкка килү, үсеше һәм тарихи бәйләнешләр ноктасыннан өйрәнүгә юл ачкан тарихилик принцибы шагыйрь тормышындагы каршылыклы, бәхәсле моментларны ачыкларга һәм төгәлләштерергә ярдәм итте.

**Төп өлеш**

Ш. Бабич үзе исән чакта 1918 елда Ырымбур шәһәренең "Дулкын" нәшриятында "Яшь Башкортстан. Зәңгәр җырлар" дигән бердәнбер җыентыгы дөнья күрә. Ул Башкортстан Республикасының Ә. Вәлиди исемендәге Милли китапханәнең кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә сакланып калган.

Бабичның үлеме – бөек шагыйрьнең һәм милли хәрәкәтнең үзәгендә торган дәүләт эшмәкәрен югалту фаҗигасе ул. Хәрби-революцион комитет, Ш. Бабичның исемен мәңгеләштерү өчен, 1919 елның 23 октябрендә Башнаркомпростан "Һәлак булган башкорт шагыйрьләре Шәехзадә Бабич һәм Габделхәй Иркәбаев истәлегенә башкорт халкы исеменнән РСФСРның югары уку йортларында укучыларга "Башкорт шагыйрьләре Бабич һәм Иркәбаев исемендәге стипендия" булдырырга дигән карар чыгара. Мәскәүдә һәм Петербургта укучы студентлар өчен елына аның күләме 25 мең, башка калаларда укучылар өчен 20 мең дип раслана.

Халык мәгарифе эшмәкәрләренең I Бөтен Башкортстан съездында 1920 елның беренче яртысында басылырга тиешле басмалар арасында "Башкорт шагыйре Бабичның биографиясе" дә була. Съезд Стәрлетамак каласында 1919 елның 27 декабреннән 1920 елның 4 гыйнварына кадәр бара. Шул ук елның мартында, шагыйрь вафатына бер ел тулган көннәрдә, Стәрлетамакта Бабич хөрмәтенә "Башкорт әдәбияты кичәсе" үтә. Кичәдә Әхмәтзәки Вәлиди, Вәлиулла Мортазин, Нуриәгъзәм Таһиров, Аллабирде Ягафаров һ.б.лар катнаша [Саламатова, С. 137-143].

Бабичның биографиясеннән башка аның көндәлекләрен, шигырьләрен, замандашларының истәлекләрен бастырып чыгару да күз алдында тотыла. Бу эшнең башында Бабичның якын дусты Төхвәт Ченәкәй тора. «Бабич үтерелү белән аны якыннан белүче шагыйрь Ченәкәй аның Оренбург һәм фронт тормышы хакында, эзеннән йөреп, 1920 елларда бай гына биографик материал туплаган, ул ук Бабичның әсәрләрен туплап биреп, Г. Ибраһимов редакциясендә аның беренче «Шигырьләр мәҗмугасы» чыгуына сәбәпче булган” [Исәнбәт, Шәехзадә Бабич]. Аңа Башкортстан китап нәшриятын булдыруда зур көч салган Давыт Юлтый, Гобәй Дәүләтшин, Ризван Алишевлар, драматург Рәүф Ниязбаев, Бабич белән якын аралашкан Сәхи Рәхмәти, Мәхмүт Мәрҗани, Шәехзадәнең агасы Фәтхелкадир Бабичев һәм Бабичны, соңгы тапкыр Ырымбурда булганда, үз йортында яшәткән дусты Габдулла Хәсәновлар булышлык итә. 1920 елның җәенә Т. Ченәкәй ике зур кисәктән торган җыентык әзерли. Берсенә Бабичның биш йөз биттән артыграк автобиографик әсәр кульъязмасы, көндәлекләре, истәлекләре, мәкалә һәм фельетоннарының кульъязмалары туплана, икенче кисәккә шагыйрьнең төрле вакыттагы кульъязма шигырьләре урнаштырыла. Мәгълүматларга караганда, кульъязманың зур өлешен шагыйрьнең беркайда да басылмаган шигырьләре тәшкил иткән.

Кече Башкортстанның башкаласы Стәрлетамакта хәлләр бик начар була. Башревком Үзәк белән килешмәү аркасында, 1920 елның 16 июнендә үз вәкаләтләреннән баш тарта. Башкортстанда яңа идарә органы - БАССРның Башкарма Үзәк комитеты булдырыла. Бабичның җыентыгын бастырып чыгару эше икенче планга күчә. Шагыйрьнең дуслары ярдәм сорап Татарстанга, "Галия"дәге укытучысы Г. Ибраһимовка мөрәҗәгать итәләр. 1922 елда Казанның 6 нчы дәүләт типографиясендә шагыйрьнең икенче җыентыгы басылып чыга һәм ул "Шигырьләр мәҗмугасе"дип атала.

Әйтергә кирәк, ул Ырымбурда һәм соңыннан, 1925 елда Мәскәүдә басылачак Бабич китаплары арасында күләме һәм тиражы ягыннан да нык аерыла: 8 бүлек, 160 битлек һәм 7 мең тираж белән басыла. Җыентыкның төзүчесе Г. Ибраһимов беренче бүлектә, Башкортстанда җыелган материалларга таянып, Бабичның биографиясен бик җентекле итеп яза. Шәехзадәнең атасы Мөхәмәтзакирның милләте буенча башкорт, анасының типтәр булуын ассызыклый. Әдәбият галиме, тәнкыйтьче һәм дәүләт эшлеклесе Г. Ибраһимовның башта “Әдәби ярдәм мәҗмугасе”нең 1 нче китабына (1921), аннары яңадан эшләп, 1922 елда чыккан “Бабич шигырьләре” җыентыгына сүз башы итеп урнаштырган “Вакытсыз һәлак булды (Тәнкыйть-тәрҗемәи халь”) язмасын, Ш. Бабич тормыш юлын фәнни ноктадан бәяләп, әдәби иҗатының төп үзенчәлекләрен ачкан, каһарман шагыйрьнең рухи мирасын киләчәктә барлау перспективаларын билгеләгән программ характердагы беренче мәкалә дип билгеләргә кирәк [Ибраһимов, б. 314-329].

Икенче бүлеккә төрле елларда язылган 4 шигыре - "Халкым өчен", "Без ни өчен кызылларга кушылдык", "Яшәсен эшчеләр", "Бер тәмсил" әсәрләре урнаштырыла. Бабичның "Башкорт халкына көйле хитап" дигән озын шигыре "Без ни өчен кызылларга кушылдык" дигән исем белән басыла. Хитапнамәнең

"Большевиклар әйтә:"Бу дөньяда ярлы халык хөкеме йөрсен", дип,

Ярлы эшчеләренең хас дошманы–буржуйларның тамыры корысын, дип.

Дутов, Колчак әйтә: эшче башына алтын таҗлы патша менсен, ди,

Патша менеп һаман Николайдай ярлы канын шулай имсен, ди.

Уйлап кара, башкорт, акылың белән кайсы тараф сиңа хәерле?

Теге торган Колчак буржуйлармы, әллә большевиклар хәерле? "

дигән 6 юл аерым шигырь итеп бирелә һәм алар хитапнамәдә юк [Саламатова, Бабичтың..., 2020, б. 137-143].

Зәбих Искужин[1] исә 1932 елда бу хитапнамәнең тулы вариантын таба һәм болай

[1] Искужин Зәбих Габделгазим улы 1911 елның 3 гыйнварында Башкортстанның хәзерге Зилаер

дип яза: "Күләме ягыннан 220 юлдан торган бу хитапнамә (ягъни зур бер дастан хәтлек дигән сүз) сәнгатьчә эшләнеше, политик зәвыге ягыннан Бабичның башка бар шигырьләреннән югары тора.<   >. Билгеле, яңа Башревкомның бу хитапнамәгә чиксез игътибар итүенең мөһим политик әһәмияте бар иде, чөнки Башкортстан белән Советлар хөкүмәте арасындагы килешү договорының 4 нче параграфында "Башкорт Хөкүмәте кызыллар ягына чыгу белән, ашыгыч рәвештә башкорт халкына һәм гаскәренә Советка каршы сугышмаска" дип хитапнамә таралыр, - диелә. Шул ук вакытта башкорт гаскәре һәм Башкорт хөкүмәте советка каршы ясаган хаталарын җыерлык практик эшләр күрсәтеп, совет каршында ышаныч казанырга тиеш иде. "Без ни өчен кызылларга кушылдык" хитапнамәсе белән Бабич әнә шул социаль таләпләргә беренче буларак ачык күңел белән тапкыр җавап биреп чыкты" [Татарстан Фәннәр академиясе... Ф. 47. Оп. 1 Д. 5. Б. 19].

Тәүге тапкыр "Газазил" поэмасының беренче бүлеге басылып чыгу белән, бу җыентыкның кыйммәте тагын да арта төшә. Г. Ибраһимов: "Газазил"нең икенче бүлеге әлегә кулда юк. Моның мөндәриҗәсе, ахыр сүзләрендә аңлашылганча, иблиснең юбилеен тасвирлаудан, шул хакта шагыйрьнең анда күргәннәрен докладтан гыйбарәт булачак" [Ибраһимов, 1922, б.142], - дип искәрмә бирә. З. Искужинның архивында, кызганычка каршы, "Газазил" балладасы очрамады. Шулай да безнең карашыбызча, бу баллада, хәтта аның икенче өлеше, Искужинның кулында булган.

Т. Ченәкәй Казанда басылган җыентыкка зур ризасызлык белдерә: "Бабичның бик аз шигырьләре генә тулысы белән, аларның байтагы, никтер, кыскартылып басылган. Мәсәлән, Бабичның "Чуар җыр" дигән озын лирик шигыре дә бар иде. Бу минем хәтеремдә калуынча, ике йөз юл чамасында иде. Шигыренең һәр куплеты алтын белән стенага язып куярлык тирән афористик мәгънәле, матур формалы, иң килешле эчке, тышкы рифмалар белән оста, шома язылган. Мин аның күп куплетларын ятлап, урыны чыкканда, дус-ишләргә сөйләп йөрим. Әнә шул озын һәм яхшы шигырьдән Г. Ибраһимов төзегән җыентыкка нибары дүрт кенә юл кертелгән һәм ул куплетка “Әллә алла, әллә иблис” дип исем бирелгән [Шәйехзада Бабич хаҡында иҫтәлектәр, 1994].

Г. Ибраһимов кулында шагыйрьнең тагын нинди әсәрләре булды икән дигән сорауга җавап мәкаләдә булып чыкты: "Минем кулымда булган Бабичның әсәрләре: "Лирика һәм көлке шигырьләре" (300 бит чамасы), "Газазил", "Йолдызлык бакчасында", "Китабеннас", "Көйләр тарихы", "Мәсәлләр", "Кандала" (кыйсса), "Ташландык вәрәкәләр", "Халык мәкальләре", "Халык әкиятләре", "Үземнең турында көлкеле тасвират", "Көлке капчыгы", "Әдәпкә сыймаган сүзләр", (боларның барлыгы меӊ ярым битләргә җыела кирәк)"[Ибраһимов, б. 329].

1957 елда "Әдәби Башкортстан" журналын-да шагыйрьнең якын дустына әверелгән укытучысы Гариф Китабовның "Бабич турында исемдә калганнар" дип аталган мәкаләсе басыла һәм ул анда шагыйрь кульязмалары язмышы хакында укытучы Х. Мөслимов сүзләрен китерә: "1920 елда Башкортстан ревкомы Шәехзадә Бабичның барлык иҗатын дәүләт милке итү турында карар чыгарган һәм җыеп бастыру өчен биш кешелек комиссия төзегән. Комиссия мәрхүмнең илебезнең төрле почмакларына таралып өлгергән бик күп әсәрләрен җыеп, басып чыгарырга әзерләнгән. Ләкин шагыйрьнең әсәрләр җыентыгын Стәрлетамакта бастырырга мөмкинлек булмаган. Шуның өчен комиссия бу җыелган дәфтәр һәм блокнотларның күчермәләрен Казанга җибәреп, анда бастырмакчы булган. Комиссия кулында Бабичның кырыклап дәфтәре һәм блокнотлары (кульязмасы) калган. Комиссия бу материалларны Стәрлетамактагы дәүләт музеена сакларга тапшырган” [Китабов, 1957]. Димәк, Г. Ибраһимовта кулында күчер-мәләр, төп нөсхәләрнең исә Башкортстанда калуы ачыклана.

Башкортстан Республикасының Ә. Вәлиди исемендәге Милли китапханәнең кульязмалар

---

районының Мәксүт авылында күп балалы гаиләдә туа. 1926-1929 елларда Кәрвансарайда, Башкорт педагогия техникумында белем ала. 1929 елның 30 сентябреннән Казанның Көнчыгыш педагогия институты студенты булып китә һәм аны 1931 елда уңышлы тәмамлый. 1932 елның көзеннән 1935 елның язына кадәр аспирантурада укый. Бер вакытта 1 нче Казан укчылар дивизиясенең 2 нче Ульянов полкында өлкән укытучы булып эшли. 1935 елның башыннан ТАССРның Язучылар союзында тәнкыйть бүлеген җитәкли. 1935 елның мартында Башнаркомпросс тарафыннан Нью-Йорк каласына ярты елга командировкага җибәрелә. Шул ук елның 7 сентябреннән 1936 елның гыйнварына тикле ТАССРның радиокомитетында "Артист Зилаир" исеме белән тапшырулар алып бара. 1936 елның 11 ноябрендә Казанда вафат була.

һәм сирәк китаплар бүлегендә сакланган “Башкортстан” газетасының 1923 елгы саннарында Бикбовның (исеме күрсәтелмәгән. – *асс. Г.С.*). “Шәехзадә Бабичның кульязмасы һәм киемнәре” [Бикбов, Башкортстан, 1923] дигән мәкаләсе басылган. Анда Ш. Бабичның киемнәре һәм кульязмалары тарихы бәян ителә: “Башкортстанны өйрәнү җәмгыятенең биргән вәкаләте буенча, шагыйребез Шәехзадә мәрхүмнең кульязмасы һәм киемнәрен эзләп табу шарты белән, Стәрлетамакка барып, бераз чараларын күргәннән соң да, кульязмаларының беразлары Стәрле музееннан табып алынды. Калганнарын Башкортстанны өйрәнү җәмгыяте әгъзасы Сәгыйт Мерәсов бу елның март аенда музейханәдән алып торып, Әгъзәм Таһировка (үзе Мерәсов әйтүенчә. *–асс. Бикбов*) китереп тапшырган. Кием һәм башка нәрсәләрен күп тикшергәннән соң, Фатима Дәүләткилдиева[2] юлдашның (иптәшнең мәгънәсендә – *асс. Г.С.*) Стәрледә Башкирское научное обществода эшләгәндә, аның карамагында булганы билгеләнде. Тик бер сандыгы Стәрледә үрнәк мәктәбе[3] мөдире Хәмит Мөслими юлдашка Наркомпросс тарафыннан 1920-21 елларга прокатка бирелеп торган икән” [Бикбов, 1923].

З. Искужинның шәхси фондына юлыккач, Бабичның Казанга, Г. Ибраһимовка җибәрелеп тә басылмый калган әсәрләре архивта килеп чыгар дигән өмет, кызганычка каршы, акланмады. Аларның аралашуын расларлык документлар архивта булмаса да, минем уйлавымча, З. Искужин Г. Ибраһимов белән очрашу эзләгән.

Бабич шигырьләренең 32 битлек “Шәехзадә Бабич шигырьләре” дигән өченче җыентыгы Мәскәүдә 1925 елда СССР халыкларының Үзәк басмасы нәшриятында 3 мең тираж белән дөнья күрә.

Ш. Бабич әдәби мирасын барлауда З. Искужин зур көч куя. Фәнни фикерләү сәләте камилләшү ноктасында гомере өзелгән яшь галимнең тормыш юлы, гыйльми мирасы һәм Ш. Бабич мирасын саклап калуга һәм яклауга керткән өлеше әдәбият галиме М. Хәбетдинова-ның “Әдәбият белемендә Зыя Искуж” мәкаләсендә җентекле яктыртыла [Хәбетдинова, 2021, Мәдәни җомга]. Галимәнең Н. Исәнбәт хатирәләрендә Бабич образының үзенчәлеген шәрехләүгә багышланган мәкаләсе дә бик кызык [Хабутдинова, 177-222 б.]

1932 елда аспирантурага укырга кергән Искужин, югалган әсәрләрне кабат эзләп табу ниятеннән, шагыйрьнең замандашлары белән очраша һәм Бабичның якын дусты, журналист Төхвәт Ченәкәй (тәхәллүс; Төхвәтулла Гыйззәтулла улы Гыйззәтуллин; 1893-1959) белән якын, дустанә мөнәсәбәт урнаштыра.

З. Искужинга Төхвәт Ченәкәй белән аралашу, әлбәттә, уңышлы була. Ченәкәй, Бабич белән 1916 елның җәеннән алып 1919 елның көзенә чаклы бергә булу сәбәпле, аның нинди әсәре һәм кайда басылганын, кемнәр белән аралашканын яхшы хәтерли. Һәм тагын да Т. Ченәкәй - Бабич әсәрләрен, көндәлекләрен һәм башка язмаларын 1919-1920 елларда җыйган, редакторлаган шәхес.

Архивта Ченәкәй язган ике хат һәм записка сакланган. Гарәп графикасында язылган бу кыйммәтле язмаларны хәзерге алфавитка З. Искужинның якташы Рәсәй фәннәре академиясе, Уфа федераль тикшеренүләр үзәге Тарих, тел һәм әдәбият институтының әдәбият гыйлеме бүлеге мөдире М. Х. Нәзерголов транслитерация ясап бирде.

Ченәкәйнең Искужинга язылган хатларының берсендә үзенең Самара аркылы аңа дәрес биргән авылга, колхозга кайтуы турында хәбәр ителә. Ул Искужинның үз туган авылын күреп китүен үтенә. Шушы уңайдан аның Ш. Бабич мирасын барлау юнәлешендәге эшенә уңай мөнәсәбәт белдерә: “Синең Бабич турында һәм башка турындагы эшләрең белән кызыксынам. Шуның өчен синең белән юлда очрашасы килә. Сау бул. Тиз күрешкәнчә. 19.07.1934” [Татарстан Фәннәр академиясе..., Ф. 47. Оп. 2 Д. 66. Б. 1].

Ченәкәй З. Искужинга Ырынбур каласында Ш. Бабичның әсәрләре турында сорашу мөмкин булган кешеләрнең исемлеген яза, шагыйрь белән бәйләнешле булган урыннарның адресларын атый, төгәлләштерә. Анда гауғалы заманда фатирында качып яткан Абдулла

[2] Дәүләткилдиева Фатима Аскар кызы – (1886 - ?, аерым бер материаллар буенча репрессия корбаны) – дәүләт эшлеклесе. 1920 елларның башында Стәрлетамакта Дәүләт музее оештырыла һәм Башревкомның 217 нче санлы карары нигезендә Фатима Дәүләткилдиева 1920 елның 22 мартыннан аның директоры итеп тәгаенләнә.

[3] Мәкаләдә сүз барган Стәрледәге үрнәк мәктәбе икенче төрле “Бабич йорты” дип аталган була. Кызганычка каршы, бу турыда Башкортстанда белүчеләр бик сирәк. Аның тәүге мөдире Сәгыйт Мерәсов. “Бабич йорты” 1924 еллар тирәсендә ябыла, дөресрәге Ленинның вафатынан соң, аның исемен мәңгеләштерү максаты белән, Бабич исеме алып ташлана һәм ул интернат тибындагы 2 нче баскычлы мәктәп итеп үзгәртелә.

Хәсәнов, шагыйрьнең фатир хуҗасы Газизә Хөсәенова, Ибраһим Бикчәнтәев, вафат булган драматург Р. Ниязбаевның хатыны Ниса Ниязбаева, Ырымбур шәһәреннән ерак түгел Имангол авылы мөәзине Абхаликов фамилияләре атала. Ченәкәй Искужинның эзләнүләрне Каргалы авылында дәвам итеп, укытучылар Сабит Марузов (яки Маруз Сабитов), "Ырынбур милләт мөселман эшләре комиссариаты мөхбире" газетасының хезмәткәре Заһит Шәрки белән бәйләнешкә кереп, шәһәр музее һәм Ырынбур аграр институты китапханәләреннән Ш. Бабич хакында мәгълүматлар еш басылган әлеге газета номерларын эзләргә тәкъдим итә [Татарстан Фәннәр академиясе... Ф. 47. Оп. 2 Д. 66. Б. 2-3].

Өч дәфтәр битенә сыйган исемлеккә кушып, хатына өстәп, туганына записка да сала. "Ырынбурга Искужин дигән бер аспирант бара. Ул Бабич турында материаллар җыячак. Син аңа булышлык күрсәт. Бигрәк тә, "Ырынбур мөселман комиссариатының мөхбире" дигән гәзитне табарга тырыш. Анда минем "Хыялбай" дигән бер шигырь бар. Шул шигырьне Бабич шигыре дип маташалар. Син бигрәк тә бу моментта булышлык күрсәтә күр" [Татарстан Фәннәр академиясе..., Ф. 47. Оп. 2 Д. 66. Б. 3 ].

1958 елда Башкортстанда, ниһаять, Бабичның "Шәехзадә Бабич. Сайланма әсәрләр" дигән җыентыгы басылып чыга. Ике ел чамасы әзерләнгән китап күп кешеләрнең тырышлыгы белән дөнья күрә. СССР Фәннәр академиясенең Башкортстан филиалы редакцион-басма советының карары буенча басылган китапка "Хыялбай"ны кертү-кертмәү турында да бәхәс булган. Мәсәлән, институт хезмәткәре А. Г. Кудашев (1912-1981) каршы чыга: "Хыялбай" шигыре үзенең формасы һәм стиле белән Ш. Бабич шигырьләренә ошамый. 1958 елның җәендә Өфегә карт татар шагыйре Төхвәт Ченәкәй килде һәм ул "Хыялбай"ның Бабичныкы түгеллеген әйтеп китте. Замандашларының (С. Кудаш, С. Рәхмәти. – *асс. Кудашев*) әйтүенә караганда "Хыялбай" тәүге тапкыр 1918 елда "Ырынбур милләт мөселман эшләре комиссариаты мөхбире" газетасында басылган. Ченәкәй әйтүенә караганда, "Хыялбай" шигыре – ул башкорт буржуаз милләтчеләре – вәлидевчеләрнең башкорт милли государствосы төзергә азаплануы турындагы хыялларын фаш итеп язылган. "Хыялбай" шигыренең тарихы шулай булуга карамастан, Әхнәф Харисов иптәш башкорт мәктәпләренең VII класс өчен төзегән хрестоматиядә дә [Башкорт мәктәпләренең VII класс өчен хрестоматия, Башкнигоиздат, 1960] "Хыялбай"ны һаман Бабичныкы дип керткән. Башкорт мәктәпләренең VII класс программасында да [Башкорт мәктәпләренең VII класс программасы, 1959] "Хыялбай" Бабичныкы итеп кертелгән һәм мондый характеристика бирелгән: "Хыялбай" дигән сатирик поэмасы. Хыялбай образында башкорт милли буржуазиясенең бөтенләйгә тар-мар ителүен гәүдәләндерү (26нчы бит. - *асс. Кудашев*). Программаның да бу өлешен Әхнәф Харисов үзе төзегән бит! [Рәсәй Фәндәр академияһының ...,Ф-50. Оп. 1. Д. 12].

"Хыялбай" шигыре, 1929 елдагы "Сәсән" журналыннан алынды дип сылтама бирелеп, җыентыкның 265-267 битләренә урнаштырыла. Журналдагы вариант белән, җыентыкта басылган вариант арасында аерма бар. Мәсәлән:

| | |
|---|---|
| *Тәүге ике юл* "Җыентык"та:<br>"Караватка барып ятты Хыялбай,<br>Башындагы хыялларын тыя алмай"<br>*Соңгы тугыз юл*:<br>Хыялбайга китәргә дә вакыт җитте.<br>Тавык җигеп тишек ялгашка парлап,<br>Хыялбай да куып китте тызылдап...<br>Хыялбайның төше шул җиргә җиткәч,<br>Калага килде керде большевиклар,<br>Атышлар башланды, китте сугышлар.<br>Хыялбайга керде мылтык ядрәсе,<br>Чыкты җаны, калды үле гәүдәсе.<br>[Шәехзадә Бабич. Сайланма әсәрләр, 1958, б. 265-267]. | "Сәсән" журналында :<br>"Караватка барып ятты Хыялбай,<br>Йөрәктәге хыялларын тыя алмый",<br>*Соңгы тугыз юл*:<br>Хыялбай да утырды - китте куалап,<br>Хаҗизар Мәккәгә җитте зарланып,<br>Хыялбай да куып китте тырылдап,..<br>Хыялбайның төше шул җиргә җиткәч,<br>Хыяллары очып җәннәткә киткәч,<br>Калага килде инде большевиклар<br>Атышлар башланып, китте сугышлар.<br>Хыялбайга тимер пуля инде - чыкты<br>Җаны чыкты да, ул җәннәткә очты [Хыялбай // Сәсән. 1929. № 2-3. Б. 21]. |

З. Искужин архивындагы "Бабич шигырьләре" дигән дәфтәрдә (Өченче дәфтәр. 1934 елның ноябреннән башланган – *асс. Г.С.*) бу шигырьнең соңгы 9 юлы 1958 елгы җыентыктагыча бирелгән һәм З. Искужин: "Хыялбай" Бабичның 1918 елда язган шигыре, ләкин Бабич аны чит кеше имзасы белән язып

тарата”, - дип ачыклык керткән [Татарстан Фәннәр академиясе..., Ф. 47. Оп. 2 Д. 66. Б. 3]. Ченәкәйнең: “Анда минем “Хыялбай” дигән бер шигырь бар” дигәнен белә торып та, Искужинның әлеге әсәрнең авторын Бабич дип куюының, безнең карашыбызча, билгеле бер сәбәпләре булгандыр. Бүгенге көн галимнәренә “Хыялбай”ның чын авторын ачыклау мәсьәләсендә эзләнүләрне дәвам итү сорала.

Ш. Бабичның “Котлау, теләк” шигыренең язылу тарихы ачыкланды. Әдәби әсәр Троицкига рус кызлар гимназиясенең 5нче сыйныфына уңышлы имтихан тапшырган Сәрвәр Әзһәмовага багышлап иҗат ителгән. Шагыйрь кызның шатлык хисләрен уртаклашканнан соң, шигыре язылган кәгазьне аның кулына тоттыра:

Кыл күперләре үтеп, ожмахка кергән төсле,
Юлга төштең, зур манигъларның үтеп иң көчлесен.
Ал кабулап, ал да сал шатлыкка чумган күңелеңә
Котлавымның эссесен һәм эче ялкын төслесен.
Син кебек зат һич вакыт калбен горурга багышламас,
Бу минем төсле газиз танышын исеннән ташламас...
(Шигырь кыскартып бирелде – Г.С.)

“Бабичның ул бүләген бик күп еллар кадерләп сакладым да, саклап кала алмадым (Казан педагогия институты аспиранты Искужинга биргәч, кире кайтарып алмадыммы, әллә 1937 елда югалттыммы, хәтерләмим. – *асс. С.Ә.*) һәм шуңа һаман җаным әрни иде, бу шигырьне Шәйхзадә Бабичның 1958 ел башкорт телендә чыккан “Сайланма әсәрләр” җыентыгында күргәч, бик шатландым. Аны укыгач, 1917 елның онытылмас язгы көне тагы бер тапкыр җанланып күз алдыма килде [Шәйехзада Бабич хаҡында иҫтәлектәр, б. 224-225].

Ш. Бабичның 1958 елда башкорт телендә чыккан “Сайланма әсәрләр”ендә Ә. Харисов та, галим Р. Бикбаев та бу шигырьнең “Имай Насыри материалларында сакланган” [Шәйехзада Бабич. Беҙ үҙебеҙ – башҡорттар..., 1994] булуын әйтәләр. Әлеге фикер төрлелеге Ш. Бабич әдәби мирасын барлау юнәлешендә эзләнүләрне тагын да активлаштырды.

З. Искужин вафат булгач, аның белән бергә аспирантурада укыган Афзал Кудашев белән Жан Локман тарафыннан язылган некрологта түбәндәге мәгълүмат теркәлгән: “Зәбих Искужин Бабич әсәрләрен редакторлый. Хәзер аның редакциясендә һәм сүз башы белән Бабичның 15 табак чамасындагы әсәрләр җыентыгы басылып ята” [Башкортстан, 1936. №271. 27 ноябрь]. Бу факт узган гасырның 50 елларында Башкортстанда Бабич әсәрләре җыентыгын әзерләгәндә, З. Искужин материаллары файдаланылганын дәлилли.

Россия Фәннәр академиясенең Уфа федераль тикшеренүләр үзәгенең гыйльми архивында Ш. Бабичның 585 биттән торган шәхси архивы саклана (Ф. 63, Оп.1, Ед.хр. 1).

Фондның зур өлешен гарәп, бер өлешен латин графикасы белән язылган Бабич әсәрләре алып тора. Фондның сүз башында узган гасырның 30 елларында Бабич шигырьләренең кечкенә өлеше язучы Имай Насыри аркылы Башкортстан Милли мәдәният тикшеренүләр институтына (хәзерге Тарих, тел һәм әдәбият институтына) килеп керә диелгән. Ә И. Насыри тарафыннан тупланган өлеше, кызганычка каршы, тәгәлләштерелмәгән: төрле кул белән язылган шигырьләрдән тыш, Бабичның “Сәсән” журналында басылган берничә әсәре бар. Бу фонд белән әүвәл 2014 елда танышканнан соң, Имай Насыри тарафыннан язылган шигырьләрне һәм З. Искужин кулы белән язылган материалны ачыклау нияте белән, аны 2020 елда, җентекләп, тагын да бер тапкыр өйрәндем.

Фондның 258 нче битеннән машинкада латин хәрефләре белән җыелган “Бабич шигырьләренә читтән кергән сүзләр” дигән кисәк башлана. Эзләнүләр әлеге 100 сүзне эченә алган сүзлекнең З. Искужин архивындагы бер дәфтәргә китереп бәйләде. Ике архивтагы сүзлекләрне чагыштырып карагач, аларның сүзгә-сүз туры килүе ачыкланды. Сүзлекнең төзүчесе булуын һәм аны 1934 елда тәмамлавын З. Искужин үзе тәгаенләп язып та куйган.

Сүзлектән соң килгән Бабичның “Яшьлек дәфтәреннән” дигән өлештә шагыйрьнең күңел җимешләре урнаштырылган. Бу кисәк язылу датасы 1911 елның май ае дип күрсәтелгән “Эй, китап” шигыре белән ачыла. Әлеге вакыт белән “Охотник”, “Бәхетсез мин” күрсәтелгән. “Яңгыр теләге”, “Син алдама”, “Ике шәкерт”, “Безнең бакча”, “Олактырылган песи”, “Гашыйк дустыма” шигырьләренең иҗат ителү вакыты 1911 елның июнь аена нисбәт ителсә, “Миңа юнь, ичмасам”, “Зарлану”, “Кәҗә белән дуңгыз”, “Күңел”, “Сабантуй”, “Габдулла әфәнде Тукаев”, “Вөждан һәм нәфес”, “Белем” әсәрләре 1911 елның июль аенда язылган дип

билгеләнгән. З. Искужинның архивында сакланган кулъязма вариант белән Бабичның фондындагы басма машинкада җыелган вариант тулысынча туры килә. Шигырь язылу вакыты, басылган матбугат төгәл күрсәтелгән.

"Яшьлек дәфтәреннән" дигән исемне, безнең карашыбызча, Бабич үзе кушкан булса кирәк. З. Искужинның бу дәфтәр белән турыдан-туры таныш булуы аның 1936 елда "Совет әдәбияты" журналы битләрендә басылган "Тукай турында Бабич" мәкаләсендәге фикер сөрешеннән аңлашыла: "Бабичның "Габдулла әфәнде Тукаев" дигән шигыре аның "Яшьлек дәфтәре"нән алынды. Ул дәфтәр исә, 1911 елның җәендә Бабич казах сахрасында йөргәндә язылган. Билгеле, 1911 ел - бу әле Бабич каләменең өйрәнчек кенә чагы иде. Ләкин монда да өйрәнчек Бабич фикерләрен шигырь белән аңлаешлы әйтеп бирә алуга, Тукайча эш иткәнен сиздереп тора. Болардан башка, Бабичның Тукай иҗатына карашын аңлаткан фикерләре, аның көндәлек дәфтәрендә һәм хатларында күренәләр. Һәм шулай ук, 1913 ел язылган булса кирәк, аның "Тукай үлде" дигән шигыре дә бар" [Искужин, 1936, б. 68].

Моннан тыш бу факт З. Искужинның язмаларында берничә урында Ш. Бабичның көндәлегенә сылтама бирүе белән дә раслана. Мәсәлән: 1) 1918 елның 5 февралендә Башкорт хөкүмәте, Дутов белән мөнәсәбәттә булуда гаепләнеп, большевиклар тарафыннан кулга алына. Бабич бу турыда: "Шул хәл Башкорт хөкүмәтенең Дутов ягына чыгып китүенә сәбәп булды" (Бабичның 1918 елгы көндәлек дәфтәре). Яки: 2) "Ул көннәрдә Бирск өязе кантон шуралары төзү эше белән командировкада йөрдем" (Бабичның 1918 елгы көндәлек дәфтәре) һ.б.лар.

Рәсәй Фәннәр академиясенең Өфе федераль тикшеренүләр үзәгенең гыйльми архивында сакланган Ш. Бабичның шәхси архивындагы латин белән машинкада басылган шигырьләре һәм Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге архивындагы З. Искужинның кулдан язылган "Бабич дәфтәрләре"ндәге әдәби әсәрләре сүзгә-сүз туры килә. Димәк, бу уртаклык әлеге материалларның З. Искужинныкы булуын раслый. Ә менә килеп эләгү юлын түбәндәгечә фаразларга мөмкин. Беренчедән, машинкада басылган архивтагы материал, төп нөсхә булмыйча, укып, төзәтмәләр кертү өчен җыелган каралама вариант, чөнки шигырьләрдә сүзләрнең язылышын төзәтү, тыныш билгеләрен кую кебек очраклар бар. Моңа ошаган каралама вариантның А. Кудашевның кулына килеп керү сәбәбен ачыклап карыйк!

Беренчедән, З. Искужин аспирантурада укыган елларда аралашкан А. Кудашевка бу материалны, Башкортстанга кайтару нияте белән, үзе бирүе дә ихтимал. Икенчедән, бу җыентыкның иң соңгы битенең артына: «Дүрт йөз сиксән өч бит номерланган. 16/XII-37 ел" («Пронумеровано четыреста восемьдесят три страниц. 16/XII-37 г.") дигән мәгълүмат язылган. Бу чорда А. Кудашев Тел һәм әдәбият гыйльми тикшеренү институты (элекке исеме. – *асс. Г.С.*) белән җитәкчелек итә. Үзе алып килмәгән очракта да, җитәкче буларак А. Кудашев Бабич шигырьләренең машинкада басылган җыентыгын төзүчесен белгән һәм З. Искужин хакында мәгълүмат биргән булырга тиеш. Билгеле булганча, 1956 елда Башкортстанда Бабичның шигырьләрен туплап һәм аны басмага әзерләү эшләре барган чакта фольклорчы галим Кирәй Мәргән (псевдоним; Кирәев Әхнәф Нурмөхәмәт улы; 1912-1984) Татарстанга Язучылар берлеге рәисе Гомәр Бәшировка хат яза: "Безне бик кызыксындырган икенче бер мәсьәлә бар: Искужин дигән бер башкорт егете элек Казанда аспирантурада укыган һәм заманында Бабич иҗаты турында диссертация язып калдырган /ул үзе очраклы үлем белән үлеп киткән. – *асс. К.М.*/. Менә шул диссертация кулъязмасын табарга ярдәм итә алмассызмы? Алынган мәгълүматларга караганда, аны Х. Хәйри иптәшнең сейфында саклана, диләр" [Рәсәй Фәндәр академияһының..., Ф-63. Оп. 1. Д. 56. Б. 1]. Әгәр дә шул вакытта З. Искужинның Бабич турындагы материаллары Башкортстанга килеп ирешкән булса, мөгаен, 1958 елда чыккан китапта аңа сылтама булыр иде.

Имай Насыри[4] әзерләгән җыентыкның тарихы тагын да аянычлырак булып чыга. Текстолог Бабичның шигырьләрен әүвәл 1929

[4] Башкорт әдәбияты тарихында "Күзәй", "Җиңелү" һ.б. талантлы әсәрләре белән киң танылган И. Насыри 1937 елның 12 декабрендә кулга алына. 1939 елның 12 мартында язучыга карата ачылган җинаять эше тәмамлана. 22 мартта гаепләү карары чыгарыла. 1940 елның 28 сентябрендә хөкем карары белән Имай Насыри 8 елга лагерьга озатыла. Башта Бәләбәй төрмәсендә утыра. Ул репрессия корбаннарыннан берсе.

елда һәм беркадәр соңрак - 1935 елда басмага әзерли. Насыри тарафыннан 1929 елда Бабич әсәрләренең басмага әзерләнүе хакындагы мәгълүмат Россия Федерациясенең Федераль иминлек хезмәтенең Башкортстан буенча идарә архивында аңа карата ачылган җинаять эшендә теркәлгән.

"1929 елда Өлкә комитеты йөкләмәсе белән мин, Насыров, һәм Кәлимуллин Бабичның әсәрләрен басмага әзерләдек, мин аның вак буржуаз милләтче шагыйрь икәнлеген күрсәтеп сүз башы яздым. Әмма аның әсәрләрен һәм юмор үткенлеген бәяләдем. Алар басылмыйча калды. Мин алга таба бу әсәрләрнең контрреволюционер хезмәтләре икәнлеген аңладым. 1935 елда мин аңардан баш тарттым (1938 елның 17 маендагы кабат сорау алулардан) (сүзгә-сүз тәрж. - *Г.С*) [РФ Федераль именлек хеҙмәтенең ... .Ф-10. В-4129. Б. 18]. Архив документларында Насыров кульямаларының Хәбиб Хәсәновта[5] саклануы һәм аның басмага бирелмәве хакында белешмә теркәлгән [ РФ Федераль именлек хеҙмәтенең..., Ф-10. В-4129. Б. 79].

Җинаять эшен тикшерүче Башкортстан дәүләт нәшрияты архивыннан Насыриның гаебен "исбатлаучы әйберләр" (вещественные доказательства. – *асс. Г.С.*) буларак 1935 елда басмага тапшырылган Бабич әсәрләренең кульязмасын алып килә. Ш. Бабич кульязмаларының, чыннан да, И. Насыров тарафыннан басмага әзерләүнүе рус теленә начар тәрҗемә ителеп беркетелгән тагын бер документ белән дә раслана. 1935 елның 8 апрелендә Башкортстан дәүләт нәшриятына юлланган бу язмада Сәйфи Кудаш И. Насыровка Бабич җыентыгын академик басма итеп чыгарырга киңәш итә. Фәнни басманы әзерләү эшенә бик җитди карап, шагыйрь әсәрләрен хронологик һәм тематик яктан системага салуның, басылу тарихын күрсәтүнең дә мөһимлеген ассызыклый. Чор идеологиясе йогынтысында Бабичның, З. Вәлидинең төп агитаторларының беренчесе булганлыгын онытмыйча, әсәрләрен пролетариат идеологиясе ноктасыннан "эшкәртергә" тәкъдим итә. Язма эчтәлегендә авторның Ш. Бабич шәхесенә һәм иҗатына тик уңай карашы һәм ихтирамы сиземләнә.

Ш. Бабич әсәрләренең басмага әзерләнгән җыентыгы шәхес культының беренче дулкынында ук кулган алынган И. Насыровка ташланган иң "зур гаепләр"нең берсе була. И. Насыри Бәләбәй төрмәсеннән, Бабич әсәрләрен басмага әзерләүдә үз сәяси хаталарын танырга мәҗбүр булып, СССР Эчке эшләр Халыклар Комиссариатына тагын бер хат яза: "Хәзер вәлидевче контрреволюционер Бабич хезмәтләрен басмага әзерләү турында. Мин бу эшкә ВКП(б) Өлкә комитетының Культпроп йөкләмәсе белән алыныум хакында төп күрсәтмәләремне бирдем. Кирәкле әйбер эшләмәгәнемне аңлау белән баш тарттым. Баш тарту хакында Башгизның баш мөхәррире Ишемгуловка гариза яздым (1935 ел)" (Сүзгә-сүз тәрҗ. – *Г.С.*) [РФ Федераль именлек хеҙмәтенең ..., Ф-10. В-4129. Б. 5 ]. Күренә ки, язучы һәм текстолог, рухи кимсетелүләргә, физик газаплауларга түзә алмыйча, Ш. Бабичны "вәлидевче", "вак буржуаз милләтче", "контрреволюционер" шагыйрь дип танырга мәҗбүр була.

Башкортстан дәүләт нәшрияты Ш. Бабич әсәрләрен нәшер итүне 1936 елгы планына керткән була. 1936 елның 1 гыйнварына Башгизның нәшер итү бүлегенә тапшырылган кульязмалар исемлегендә Бабичның китабы да бар. "Бабич әсәрләре" җыентыгының авторы И. Насыри белән нәшрият арасында төзелгән 214нче номерлы договор саклана (датасы куелмаган. - *асс. Г.С.*). Договорның хакы - 5400 сум, авторның 25 процент аванс алуы әйтелә [Башкортостан Республикаһының Милли архивы. Ф-749. Оп. 1. Д. 141. Б. 171 ]. Димәк, И. Насыриның "баш тарттым, эшләмәдем" дигән сүзләре дөреслеккә туры килеп бетми, башланган эшне азагына кадәр эшләп бетермәве дә ихтимал.

Бу эзләнүләр, узган гасырның 30 нчы еллары башында Башкортстанда Ш. Бабичның әсәрләрен туплау һәм бастыру эше киң җәелдерелсә дә, хәзерге көндә сакланып калган, Башкортстан һәм Татарстанда нәшер ителгән китаплардагы әдәби әсәрләр, башлыча, Зәбих Искужин әзерләгән җыентыктан алынган дигән нәтиҗә ясарга нигез бирә. И. Насыри нәшер итәргә әзерләгән җыентык шул җинаять эшенә беркетелгән "исбатлаучы зат" (вещественные доказательства) юкка чыккан, чөнки судтан соң "исбатлаучы әйберләр" хуҗасына тик гариза буенча гына кайтарыла, ә таләп итүче булмаса,

[5] Хәсәнов Хәбиб Вәли улы – (1899-1938) –җәмәгать эшмәкәре, тәржемәче, рус - башкорт сүзлегенең редакторы. Ул бу вакытта төрмәдә утыра. 1938 елның 10 июлендә 44 шәхескә үлем карары чыгарылган исемлектә аның да фамилиясе була. Репрессия корбаны.

юк ителәләр. Безнең карашыбызча, 1937-1938 елларда Бабичның җыентыгын кайтаруны таләп итеп, судка һәм тикшерүче органнарга гариза язучылар булмаган.

Безнең фикер Имай Насыри хатынының 1957 елда СССР Язучылар берлеге каршындагы авторлар хокукын саклаучы Бөтенсоюз идарәлегенә язган хаты белән дә раслана. “Татар матбугатында басылган һәм өлешчә нәшер ителмәгән шигырьләренең минем ирем тарафыннан тупланып, 30 елларда тәкъдим ителгән Бабич әсәрләре, чыннан да, шагыйрь рухи мирасының шактый зур өлешен алып тора. Әмма мин аларның басмага әзер түгел җыентык булуына ышандым: материал җыентыкка җитәрлек дәрәҗәдә түгел, Бабич әсәрләренең чыганагы яки кайдан күчерелгәнлеге күрсәтелмәгән, шигырьләр оригиналлар белән чагыштырылмаган, бөтен материал кулланылыштан чыккан гарәп һәм латин хәрефләрендә бирелгән” (сүзгә-сүз тәрҗ. – *Г.С.)* [Рәсәй Фәндәр академияһының... . Ф-50. Оп. 1. Д. 83. Б. 1].

З. Искужин Ш. Бабич иҗаты белән җитди кызыксынып китеп, аның рухи мирасын тикшерүгә багышланган фәнни диссертация яза. Кызганычка каршы, гыйльми хезмәтнең төп өлеше сакланмаган, шулай да берничә кисәге дәфтәрләрендә сакланып калган. Аспирант шагыйрь иҗатын тикшерүнең алты юнәлешен билгели: 1. Бабич – Октябрь революциясе алдыннан татар, башкорт иҗтимагый дөньясының вак буржуаз демократик шагыйре; 2. Бабич иҗатында реализм; 3. Бабич лирикасы; 4. Бабич сатирасы; 5. Бабичның шигъри теле; 6. Бабич һәм халык әдәбияты. 7 нче тема итеп "Революциягәчә бездә шигырь культурасы һәм Бабични өйрәнү" мөмкинлеген искәртеп куя. З. Искужин шагыйрь иҗатына комплексլы якын килү методының нәтиҗәлелеген ассызыклый: “Бабич иҗатын җыю, барлау һәм өйрәнү өчен телче яки әдәбиятчы булу гына аз. Тарихчы һәм политик булу кирәк" (Соры тышлы блокноттагы язма – *асс. Г.С*). Башкорт милли хәрәкәтенең каһарманы Бабичның гомер юлын һәм иҗатын өйрәнгәндә, яшь галим мөһим чыганакларның берсе итеп Кәрим Иделгужин авторлыгында чыккан "Башкирское национальное движение в 1917-1920 // Тезисы Башобком ВКП (б)” хезмәтен файдалана [Иделгужин].

Ш. Бабич тормыш юлындагы вакыйгаларны, 1917 елгы Октябрь борылышыннан соңгы иҗтимагый-сәяси вазгыятькә, тарихи барышка аның мөнәсәбәтен өйрәнү һәм әлеге гаугалы заманда язылган әдәби әсәрләрен барлау юнәлешендәге эзләнүләр хәзерге вакытта да дәвам итә. Сөенечкә каршы, яңадан-яңа, бик тә әһәмиятле фактлар, мәгълүматлар табыла. Мәсәлән, Ш. Бабичның “Башкорт халкына” дигән шигыренең гыйбрәтле язмышы шуның ачык мисалы булып тора. Моңа кадәр әлеге әсәрнең шагыйрь тарафыннан иҗат ителүе мәгълүм булса да, әсәрнең тексты билгеле түгел иде. Зәбих Искужин үлгәннән соң, галимнең язмалары кулдан-кулга күчеп йөри торгач, архивының бер кече өлеше Татарстан халык язучысы, драматург, шагыйрь, фольклорчы, тәрҗемәче Нәкый Исәнбәткә килеп эләгә. Шәехзадә Бабичның "Башкорт халкына" дигән шигыре дә бу материаллар арасында була. Галим карашынча, “Бабичның иң мактаулы шигырьләре рәтендә торырга тиеш булган бу әсәр әлегә кадәр беркайда матбугатта басылмаган. Шуңа күрә төп тексты кулда юк, бары тик шул башкортлар Совет ягына чыкканда, Бабич белән бергә булган иптәшләрнең хәтерләве буенча алына" [Исәнбәт, 2021].

Ниһаять, бу шигырь башкорт һәм татар халкына барып ирешеп, зур яңгыраш алды.

Ш. Бабич кыска гомер юлының соңгы көннәре, фаҗигале үлеме хакында да төрле карашлар яши. Монографик хезмәтләрдә, төрле чыганакларда каһарман шәхеснең вакытсыз һәм фаҗигале үлеменең дә төрле версияләре күрсәтелә [Гыйльманов, 1990, б. 12], [Гайнетдинов, б. 224], [Ганиева, б. 140], [Бабич, 2009, б. 140-141], [Гайнетдинов, Ганиева, б. 351-352], [РФ Федераль именлек хеҙмәтенең …, Ф-10. В-4129. Б. 5] һ.б.лар.

М. Хәбетдинова Н. Исәнбәт архивы материалларын өйрәнгәндә, Ш. Бабичның соңгы көннәренә һәм фаҗигале үлеменә ачыклык кертә торган мәгълүматларга юлыга: “Н. Исәнбәт Зыя Искуж хатирәләренә таянып, Ш. Бабичның кемнәр тарафыннан һәм ничек үтерелүе турында яза. Зыя Искуж Ш. Бабичның 1919 ел март азагында Преображенский Ревкомы тарафыннан үтерелүе турында көндәлегендә язып калдырган” [Хәбетдинова, 2021]. Галимә сүзләренә караганда, күренекле татар язучысы һәм галиме Н. Исәнбәт архивында 1965 елның 10 гыйнварында тәмамланган 77 битлек “Шәехзадә Бабич” хезмәтенең машинкада басылган кулъязмасы саклана. М. Хәбетдинова “Мәдәни җомга”

газетасының 2021 ел 15 гыйнвар санында Н. Исәнбәтнең “Бабичның үтерелүе” дигән язмасын тәкъдим итте. Бу мәкалә галимнең үз сүзләре белән әйткәндә, “үтерелүе шактый томанлы” булган Ш. Бабич фаҗигасенә ачыклык кертә. Н. Исәнбәт бу гаделсезлеккә тарихи чынбарлык, сәяси ноктадан якын килеп, З. Искужин материалыннан өзек китерә. «Бабич 1919 ел март азагында, җирле халыкка милли антагонистик тактика тотучы Преображенский Ревкомы тарафыннан үтерелә” [Кара: Исәнбәт, 2021]. Аңлашылмаучылыкка урын калдырмас өчен, мәкалә авторы бу Ревкомның социаль йөзе турында В.В. Куйбышев хитапнамәсеннән өзек китерә. “ Кайбер совет учреждениеләренең җирле (төп, асаба, – *асс. Н.И.*) халыкка ышанмый караулары аркасында «Саф рус Ревкомнары төзелеп, элек башкорт халкын эксплуатировать итүче, аңа дошманлык саклаучы көчеп килгән кулак элементлары кереп утырган. < > Җирле халыкка җинаятьлек эшләүче элементлар тарафыннан Башкортстанның революцион деятельләре, шагыйрьләре, художниклары атылганнар» [Кара: Исәнбәт, 2021]. Н. Исәнбәт З. Искужинның документаль чыганакларыннан тыш башкорт матбугатында соңгы игълан ителгән өстәмә материалларны да өйрәнеп, болай дип яза: “Бабичның милли дошманлык, шовинизм һәм бөек державиячелек шаукымнары нигезендә үтерелгән булуы аларда да раслана һәм тагын да тулылана төшә” [Исәнбәт, 2021].

## Нәтиҗәләр

1. Ш. Бабич казах-кыргыз, татар, башкорт халыкларының милли һәм мәдәни традицияләрендә тәрбияләнеп, алардан рухи азык алып, кыска вакыт эчендә киңкырлы, иҗади шәхес булып формалаша һәм аларның әдәбияты һәм сәнгатьләре үсешенә зур өлеш кертә.

2. Шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗаты тарихи барышның бик катлаулы, гаугалы чорына туры килә. Болгавыр һәм зур афәтләр заманы шагыйрьнең тарихи һәм идеологик ориентирларын сайлауны, милли ышанычларын һәм романтик идеалларын тормышка ашыруны катлауландыра. Төрки-тугандаш халыклар мәдәниятендә Бабичның тоткан урынын, шәхес кыйммәтен һәм шигъриятенең әһәмиятен билгеләүгә иҗтимагый-сәяси җилләр зур йогынты ясый.

3. Ш. Бабич тормыш юлын һәм әдәби эшчәнлеген иҗтимагый-сәяси вазгыять һәм мәдәният контекстында тикшерү кискен социаль һәм мәдәни үзгәрешләрнең әдипләр каләменә һәм тормышына зур йогынты ясавын күрсәтә. “Күчеш” чорында милли сүз сәнгатенең үсеш тенденцияләрен, язучы-шагыйрьләрнең идеологик ориентирлары, рухи кыйблалары үзгәрешен ачыкларга ярдәм итә.

4. Ш. Бабичның әзерләнеп тә басылмый калган җыентыкларының катлаулы тарихы бар. Татар һәм башкорт халкының зыялы шәхесләренең каһарман шагыйрьнең тормыш юлын ачыклау һәм әдәби әсәрләрен барлау юнәлешендәге изге гамәлләре И.В. Сталин шәхес культы елларында “зур җинаять” төсендә бәяләнә һәм аларның репрессияләнүенә китерә.

## Йомгак

Күзәтүләр Ш. Бабич тормышын һәм рухи дөньясын өйрәнүнең бер гасырлык тарихы барлыгын күрсәтә. Шунысы кызганыч: бик тиз вакыт эчендә милләтпәрвәр, эзләнүчән каләм иясе булып җитешкән Ш. Бабич социаль катаклизмнар, идеологик көрәш, террор корбаны була. Шагыйрь шәхесен иҗатын бәяләүнең төрле баскычлары булса да, ул берьяклы, ялгыш бәяләүдән, бер чиктән икенче чиккә ташланулардан объективлыкка таба хәрәкәт итә. Бу юнәлештә эзләнүләрне, һичшиксез, дәвам итү сорала, шуның белән мәкалә темасының киләчәктә өйрәнелү перспективасы билгеләнә.

**Әдәбият**


*Әгъләм М.* Татарның танылмаган мәшһүр заты // Казан утлары. 1995. № 1. Б. 160-164 б.

*Бабич* // Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда: 1 том / төз. Р.Н. Даутов, Р.Ф. Рахмани. Казан: Татар.кит.нәшр., 2009. Б. 139-142.

*Бабич Ш.* Шәехзадә Бабич шигырьләре. М.: СССР халыкларының Үзәк басмасы, 1925. Б. 32.

*Бабич Ш.* Беҙ үҙебеҙ – башҡорттар: шиғырҙар, поэмалар, фельетондар, мәҡәләләр, хаттар, көндәлектәр [Төҙ., баш һүҙ, һәм аңл. авторы Р. Бикбаев]. Өфө: Китап, 1994. Б. 583.

*Бабич Ш.М.* Зәңгәр җырлар [Төз., кереш мәкалә авторы Г. Гыйльманов]. Казан: Татар.кит.нәшр., 1980. Б. 542.

*Бабич Ш.М.* Исемнәр бакчасы. Шигырьләр, эпиграммалар. Казан: Татар.кит.нәшр., 1997. Б. 111.

*Бабич Ш.М.* Сайланма әсәрләр. Казан: Татар.кит.нәшр., 1958. Б.154.

Башҡортостан Республикаһының Милли архивы. Ф-749. Оп.1.Д.141. 171.

*Бикбов.* Шәйехзада Бабичтың ҡулъяҙмаһы һәм кейемдәре // Башҡортостан. 1923. 3 б.

*Гайнетдин М.В* Бабич һәм аның китабы // Казан утлары. 1991. № 11. Б. 186-188.

*Гайнетдин М.В.* Шәехзадә Бабич // Хакыйкать юлыннан. Казан, 2001. Б. 206-224 б.

*Гайнетдинов М., Ганиева Р.* Шәехзадә Бабич // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. 4 т.: XX йөз башы / [төз. Р.Ф. Рахмани; фәнни мөх. Р.К. Ганиева]. Казан: Татар.кит.нәшр., 2016. Б. 340-352.

*Ганиева Р.К.* Романтические мотивы творчества Шаехзаде Бабича // Татар әдәбияты: традицияләр, багланышлар. Казан, 2002. Б. 122-141.

*Госман Х.* Егерменче елларда татар поэзиясе. Казан: Казан университеты нәшрияты, 1964. 397 б.

*Гыйльманов Г.* Кояшлы шигърият // Зәңгәр җырлар. Казан, 1990. Б. 7-14.

Зәңгәр җырлар / Төз. , кереш мәкалә авт. Г. Гыйльманов. Казан: Татар.кит.нәшр., 1990. 543 б.

*Гыйльманов Г.* Мәхәббәт тоткыны // Исемнәр бакчасы. Шигырьләр, эпиграммалар. Казан, 1993. Б. 5-14.

*Заһидуллина Д.Ф.* Шаехзадә Бабичның иҗат юлы: мәгърифәтчелектән шартлы сурәткә таба // Рәмиев С.Л., Бабич Ш.М. Әсәрләр. Казан, 2005. Б. 149-166.

*Ибраһимов Г.* Вакытсыз һәлак булды // Әсәрләр сигез томда. 5 т.: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр хезмәтләр (1910-1933) [төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. М.Х. Хәсәнов, Р.Р. Гайнанов]. Казан: Татар.кит.нәшр., 1978. Б. 314-329.

*Иделгужин К.* Башкирское национальное движение в 1917-1920 // Тезисы Башобком ВКП (б). Уфа: Изд-во Баш. ЦИК, 1934.

*Исәнбәт Н.* Бабичның үтерелүе // Мәдәни жомга. 2021. 15 гыйнвар. №1 (10 гыйнвар, 1965, Казан).

*Исәнбәт Н.* Шәехзадә Бабич. Архив материалы, кулъязма, 57 б.

*Искужин Зия Газимович //* URL: Центр письменного и музыкального наследия ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (miras.info).

*Искужин З.* Тукай турында Бабич // Совет әдәбияты. 1936. №5. Б. 67-68.

*Исәнбәт Н.* Шәехзадә Бабич: Истәлек // Казан утлары. 1967. №6. Б.127-134.

*Китабов Ғ.* Бабич тураһында иҫемдә ҡалғандар//Әҙәби Башҡортостан, Өфө, 1957. №4. Б. 41.

*Кудашев А., Локман Җ.* Некролог (З. Искужин) // Башкортостан, 1936. 27 ноябрь (№271).

*Миңнегулов Х.Й.* Олуг талант (Шәехзадә Бабич турында) // Мирас. 1995. № 9. Б. 46-61.

*Нәҙерғолов М.* Уйландыра, иҫкәртә, һабаҡ бирә // Әбүс. Яҙмалар. (төҙөүсеһе - Янбаев И.К.). Өфө: Китап, 2007. 309 б.

*Нуруллин И.* XX йөз башы татар әдәбияты.Урта мәктәп укытучылары, студентлар һәм югары класс укучылары өчен дәреслек-кулланма. Казан: Татар.кит.нәшр., 1982. Б. 222-225.

РФ Федераль именлек хеҙмәтенең Башҡортостан буйынса идаралығы архивы. Ф -10. В-4129.

Рәсәй Фәндәр академияһының Өфө федераль тикшеренеүҙәр үҙәгенең ғилми архивы. Ф-50. Оп. 1. Д.12.

*Саламатова Г. Д.* Ш. Бабичтың әҙәби мираҫының яҙмышы (1918-1937 йылдарҙағы осор) // Актуальные проблемы национальных литератур и отечественного литературоведения: материалы Всероссийской научно-практической конференции (с международном участием), посвященной 125 – летию со дня рождения видного башкирского поэта, общественного и государственного деятеля Шайхзады Бабича: Уфа: РИЦ БашГУ, 2020. Б. 137-143.

*Татар поэзиясе антологиясе*. 1 китап. Казан: Татар.кит.нәшр., 1992. Б. 452-461 б.

*Татар әдәбияты тарихы*: 6 томда. 3 т.: XX гасыр башы. Казан: Татар.кит.нәшр., 1986. Б. 247-251.

Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге. Ф. 47. Оп. 1 Д. 5.

Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге. Ф. 47. Оп. 2. Д. 66.

*Харрасова Р.* Фәрваз Миңнуллин – тәнкыйтьче // Фәрваз Миңнуллин (1934-2009). Казан: РИЦ «Школа» 2019. Б.3-13.

*Хабутдинова М.М.* Образ Ш. Бабича в воспоминаниях Н. Исанбета // Актуальные проблемы национальных литератур и отечественного литературоведения: материалы Всероссийской научно-практической конференции (с международном участием), посвященной 125 – летию со дня рождения видного башкирского поэта, общественного и государственного деятеля Шайхзады Бабича: Уфа: РИЦ БашГУ, 2020. Б. 197-222.

*Хәбетдинова М.М.* Әдәбият белемендә Зыя Искуж // Мәдәни җомга. 2021. 15 гыйнвар. №1.

Шәйехзада Бабич хаҡында иҫтәлектәр. Өфө: Китап, 1994.

*Эпик шигърият.* XX йөз башы. / Төз.: Ф.З. Яхин. Казан: ТаРИХ, 2002. Б. 17-31.

# НАСЛЕДИЕ ШАЕХЗАДЕ БАБИЧА В КОНТЕКСТЕ КУЛЬТУРНОЙ И ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКОЙ ЖИЗНИ 1920–1950 ГГ.

**Гульсясяк Давлетбаевна Саламатова,**
Уфимский государственный институт искусств им. З. Исмагилова,
Россия, 450008, г. Уфа, ул. Ленина, д. 14,
gulsyasyak.salamatova.76@mail.ru.

В статье жизненный и творческий путь башкирского и татарского поэта Шаехзаде Бабича рассматривается в культурном контексте эпохи. Систематизированы новые источники о жизни поэта, обнаруженные в государственных и частных архивах, газетно-журнальных публикациях, воспоминиях и письмах. Уделяется особое внимание истории создания отдельных произведений, уточняется хронология. Выявлен вклад Г. Ибрагимова, З. Искужина. Т. Ченекея, А. Кудашева, А. Насыри, Н. Исанбета и др. в сохранение духовного наследия Шаехзаде Бабича. Вводятся в научный оборот новые факты о жизни этих общественных деятелей. Доказана неразрывная связь издательской судьбы произведений Ш. Бабича с идеологическим и политическим климатом в нашей стране.

**Ключевые слова:** башкирская литература, татарская литература, рукописи, социально-общественная обстановка, культура.